ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Чехов ур., 18 нче йорт, Югары Ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39, E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ с. Верхний Услон _______________

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Олы Меми авыл җирлегенең генераль планы проектын карау буенча
иҗтимагый фикер алышуларны билгеләү турында

Югары Ослан районында яшәүчеләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдә катнашуга хокукларын гамәлгә ашыру максатларында, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2013 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында” 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы, Югары Ослан муниципаль районы Советының 2020 елның 4 июнендәге 58-670 номерлы карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районында иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегенең генераль планын карау буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Әлеге карарның 1нче пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы итеп Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген (алга таба - иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы) билгеләргә.

2.2. Иҗтимагый фикер алышулар уздыру вакыты - 2024 елның 11 октябреннән 2024 елның 9 ноябренә кадәр;

3. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга:

3.1. Әлеге карарның 1нче пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны үткәрүне тәэмин итәргә.

3.2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәрне Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3.3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге генераль планы проектын һәм аңа мәгълүмати материалларны 2024 елның 11 октябреннән дә соңга калмыйча Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегенең барлык торак пунктларында да проектлар буенча экспозицияләр оештырырга.

Тәкъдимнәр, искәрмәләр кабул ителә:

1) Югары Ослан муниципаль районының http://verhniy-uslon.tatarstan.ru/ рәсми сайты аша;

2) иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы адресына язма рәвештә

Татарстан Республикасы, Югары Ослан ав., Чехов ур., 18, яисә Олы Меми авыл җирлегенең Башкарма комитетына Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Олы Меми авылы, Яшьләр ур., 19 йорт адресы буенча;

3) җәмәгать фикер алышуларында каралырга тиешле проект буенча экспозициягә килүчеләрне исәпкә алу журналында язылу юлы белән.

3.4. Иҗтимагый фикер алышулар тәмамлангач, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында беркетмә әзерләргә һәм җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләре турында йомгак ясап урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы Е.А Варакин